ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
29.06.2024

**К А Р А Р**
№ 607

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 маендагы 654 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 маендагы 654 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы турындагы нигезләмәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. РСЧС ТП вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре кергән Биектау муниципаль районының идарә органнарын, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары көчләрен һәм чараларын берләштерә һәм "Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" Федераль законда каралган бурычларны үтәү максатларында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.»

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы турындагы нигезләмәнең 12 пунктында беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Авария-коткару хезмәтләрен һәм авария-коткару формированиеләрен гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә җәлеп итү "Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында" Федераль законның 13 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин